«Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле
гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

Килешенде:
Өлкән тәрбияче
_______ Хөснетдинова Д.Р.
«_31_» _____08_____ 2022 ел

Раслыйм
«Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы»
МБМББ житәкчесе :
_______ Габидуллина Э.С.
«_31_» _____08_____ 2022 ел

# 11нче беренче кечкенәләр (2-3 яшь) төркеменең 2022-2023 нче уку елына эш программасы

Төзүчеләр:
Вахитова Әлфия Равил кызы
Гатина Фирдания Нургали кызы

Яр Чаллы
2022 ел

1

**Эчтәлек**

1. Максатлар бүлеге.................................................................................................3
1.1. «Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы турында гомуми белешмә.....................................4
1.2. Төркем турында белешмә......................................................................................4
1.3. Программаның максатлары һәм бурычлары ...........................................................4
1.4. Программага хас үзенчәлекләр ............................................................................5
1.5. Беренче кечкенәләр төркеме эшчәнлегенең юнәлеше...............................................8

2. Эчтәлек бүлеге.....................................................................................................8
2.1. Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары ...............................................................................8
2.2. 2 яшьтән алып мәктәп яшенә кадәрге балаларның үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирү эшчәнлеге.....................................................................................................8
2.3. Психологик-педагогик эш эчтәлеге
2.3.1.«Социаль-коммуникатив үсеш» белем бирү өлкәсе.................................................9
2.3.2. «Танып-белү үсеше» белем бирү өлкәсе ………………..……………..……...22
2.3.3. «Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе……….……………………….………35
2.3.4. «Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсе………………..……….……...48
2.3.5. «Физик үсеш» белем бирү өлкәсе……………………………..……….……54
2.4. Ата-аналар белән эш...........................................................................................60

3.Оештыру бүлеге....................................................................................................62
3.1. Көндәлек режим.................................................................................................62
3.2. Методик программа белән тәэмин ителеш ............................................................63
3.3. Предметлы тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре..................................................63
3.4. Материаль-техник тәэмин ителеш...........................................................................65

Кушымта
Кушымта 1. Балаларның яшь үзенчәлекләре ..................................................................66
Кушымта 2. Белем бирү эшчәнлегенең тематикасы.........................................................67
Кушымта 3. Белем бирү эшчәнлеге челтәре ....................................................................68
Кушымта 4. Сәламәтләндерү чаралары ..........................................................................69
Кушымта 5. Милли–җирле компонент (УМК) .................................................................72

## 1.Максатчан бүлек

Бу программа ФДББСна нигезләнеп эшләнгән Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге “Туганнан алып мәктәпкәчә” төп гомуми мәктәпкәчә төп белем бирү программасына таянып төзелде.

Эш программасы түбәндәге норматив документларга таянып төзелде:

1. Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» с изменениями и дополнениями от 14.07.2022 №298, №299, №300
2. Федеральный закон от 03.08.2018 №317-ФЗ «О внесении изменений в статьи 11 и 14 Федерального закона «Об образовании в Российской Федерации»;
3. Комментарии к ФГОС дошкольного образования Минобрнауки России, Департамента общего образования от 28.02.2014 г. №08-249;
4. Профессиональным стандартом "Педагог (педагогическая деятельность в сфере дошкольного, начального, основного и среднего общего образования) (воспитатель, учитель)", утвержденного приказом Минтруда и Соцзащиты РФ № 544н от 18 октября 2013 г. (с изм. на 5.08.2016г);
5. СанПиН 2.4.3648-20 от 28 сентября 2020 г «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодёжи»;
6. СанПиН 2.3/2.4.3590-20 "Санитарно-эпидемиологические требования к организации общественного питания населения" от 27 октября 2020 г. № 32;
7. СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или) безвредности для человека факторов среды обитания» от 28.01.2021 № 2;
8. Санитарно-эпидемиологические правила СП 3.1/2.4.3598-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации работы образовательных организаций и других объектов социальной инфраструктуры для детей и молодежи в условиях распространения новой короновирусной инфекции (COVID-19)», утвержденный постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 30 июня 2020 года №16.
9. Приказ Министерства просвещения РФ от 31.08.2020г. № 373 «Об утверждении Порядка организации и осуществления деятельности по ООП – образовательным программам ДО»;
10. Методическими рекомендациями Минобрнауки «О разработке основной общеобразовательной программы дошкольного образования» от 21 октября 2010 года, № 03-248;
11. Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» от 08.07.1992 №1560-XII (изменения и дополнения от 27.04.2017 г. №27-ЗРТ);
12. Закон Республики Татарстан «Об образовании» от 22.07.2013 г. №68-ЗРТ (принят Государственным Советом 28.06.2013 г.);
13. Устав муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения города Набережные Челны «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по познавательно-речевому направлению развития детей № 49 «Гульназ», постановление от 22 сентября 2017 г. № 5633;
14. Примерная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы» под редакцией Н.Е.Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой, 2020 г.
15. «Основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад № 49 «Гульназ», приказ № 192 от 31 августа 2020 года.

## 1.1. Гомуми белешмә

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:**
«Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү оешмасы.
**Кыскача атамасы:** «Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы МБМББУ.
**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы:**
*субъект РФ:*Татарстан Республикасы
*индекс*: 423828
*торак пункты:* Яр Чаллы шәһәре
*урам:Шамил Усманов*
*йорт: 133*
*шәһәрнең федераль телефон коды: (*8552) *телефон:* 42-65-92
*факс:* 42-65-92 *e-mail*: det.sad49@mail.ru
сайт: https://edu.tatar.ru/n_chelny/page92698.htm
**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының җитәкчесе:**
Габидуллина Эльза Сагил кызы
**Балалар бакчасы эшчәнлегенең юнәлеше:**
1.Танып белү-сөйләм үсеше, социаль-шәхси үсеш, физик үсеш, нәфис-нәфәсәти үсеш.
2.Мәктәптә укырга әзерләү (логик фикерләү, уку грамотасы...)
3.Сәламәтләндерү һәм авырулардан профилактика чаралары.

Балалар бакчасы 5 көнлек эш атнасында 6.00-18.00 сәгатькә кадәр эшли.

## 1.2. Төркем турында белешмә
### Төркемнең составы

| №гр | Яше | Саны | Малайлар | Кызлар |
|---|---|---|---|---|
| 11 | 2-3 | 14 | 6 | 8 |

Балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, тәрбия һәм белем бирү процессының сыйфатын яхшырту максатында балалар бакчасы үз алдына түбәндәге бурычларны куя:
1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.
2. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем стандартларына (ФДББС) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.
3. Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.
4. «Татарстан Республикасы халыклары телләре» турындагы законны тормышка ашыруда яңа алымнарны куллану һәм укыту-методик комплекты аша балаларның сөйләмен сыйфатлы камилллләштерүне дәвам итү
Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге кабинетлар бар: татар теле кабинеты, музыка һәм физкультура залы, ИЗО кабинеты, музей.

## 1.3 Программаның төп максатлары һәм бурычлары

**Программаның төп максатлары** - мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру, шәхеснең база культурасы нигезләрен формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү, хәзерге җәмгыятьтәге тормышка әзерләү, уку эшщчәнлегенә алшартлар

формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү. Программада баланың шәхесен үстерүгә, балалоарның сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотизм, актив тормыш позициясе, тормышта килеп туган төрле хәлләрдән чыгу юлларын баба белү, традицион кыйммәтләргә карата хөрмәт кебек сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирелә. Бу максатлар бала эшчәнлегенең төрле төрләре: уен, аралашу, хезмәт, танып-белү-тикшеренү, продуктив (рәсем ясау, конструктив һ.б.), музыка белән шөгыльләнү, уку процессларында тормышка ашырыла.

**Бурычлар:**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру.

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче дәрәҗә ия:

- һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту;
- төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергә ярдәм итәрлек кешелеклде һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбия-белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү;
- тәрбия-белем бирү процессын иҗади оештыру;
- белем бирү материалын куллануның вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү;
- балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм гаилә шартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;
- балалар бакчасы һәм башлавнгыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлегендә акыл һәм физик яктан көч килүләрне булдырмаучы, предметлы укыту басымы ясамауны тәэмин итүче дәвамчанлыкны үтәү;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

## 1.4 Программага хас үзенчәлекләр

***Бала шәхесен үстерүгә юнәлгәнлек***

Программаның өстенлеге — ирекле, үз-үзенә ышанган, актив тормыш позициясенә ия, тормыштагы төрле хәлләрдән чыгу юлларын табуга иҗади килергә омтылган, үз фикере булган һәм аны яклый белә торган кеше тәрбияләү.

***Программаның патриотик юнәлгәнлеге***

Программада балаларда Туган илгә карата мәхәббәт, патриотик хисләр, Ватанның казанышлары белән горурлану, Россиянең героик үткәне һәм бәхетле киләчәге булган күпмилләтле бөек ил икәнлегенә ышаныч тәрбияләүгә зур игътибар бирелә.

***Әхлакый тәрбиягә, традицион кыйммәтләрне яклауга юнәлгәнлек***

Ата-анага мәхәббәт, өлкәннәргә ихтирам, кечкенәләргә, олы яшьтәге кешеләргә карата кайгыртучан мөнәсәбәт кебек традицион кыйммәтләргә хөрмәт тәрбияләү; традицион гендер күзаллаулары булдыру; балаларның үз гамәлләрендә уңай үрнәккә иярү омтылышын тәрбияләү. Алга таба укуны дәвам итү максатын кую Программа балаларда танып белү кызыксынучанлыгын үстерүгә, белем алу омтылышына, алга таба бөтен тормышы буена укуга (мәктәптә, институтта һ.б.) карата уңай мотивациягә; барлык кешеләргә дә белем алырга кирәклекне аңлауга юнәлтелгән. Белем алуга карата аны иң мөһим тормыш кыйммәтләренең берсе итеп карауны формалаштыру.

***Балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлгәнлек***

Программа тәрбиячеләр алдына куя торган төп бурычларның берсе — балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларда сәламәт яшәү рәвеше турында элементар күзаллаулар булдыру, уңай гадәтләр, шул исәптән дөрес туклану гадәте, хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ тәрбияләү.

***Баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алуга юнәлгәнлек***

Программа һәрбер баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән, аңа исә тормыш эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрендә дә (көндәлек режимны баланың индивидуаль үзенчәлекләренә якынайту һ.б.), бала белән үзара аралашу формаларында һәм ысулларында да (аның индивидуальлегенә карата хөрмәт, эмоциональ халәтләренә игътибарлылык, үз-үзенә ихтирамлылык хисләрен яклау һ.б. ш.) балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу хисабына ирешелә.

***Тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән үзара бәйләнеш***

Программа гаиләнең уникаль тәрбия институты буларак кыйммәтен һәм тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы һәм тыгыз мөнәсәбәтләр булдыру кирәклеген ассызыклый. «Балалар бакчасының гаилә белән бәйләнешы» бүлегендә тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары белән төп эшләү формалары тасвирлана, аларны куллану педагогларга мәктәпкәчә белем бирүнең гомуми мәгариф программасын уңышлы гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә. Бала белән өйдә шөгыльләнү өчен кулланмалар — «Җиде Гном мәктәбе» сериясеннән китаплар белән тәэмин ителү Программаның мөһим өстенлеге булып тора.

**Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**
**Максат ориентирлары**

Мәктәпкәчә балачакның үзгәлеге (бала үсешенең сыгылмалылыгы, аның үсеш вариантларының төрлелеге, аның табигыйлеге һәм нәрсәгә дә булса бәйле булуы) мәктәпкәчә яшьтәге баладан конкрет белем бирү нәтиҗәләренә ирешүне таләп итәргә мөмкинлек бирми һәм мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләрен максат ориентирлары рәвешендә билгеләү зарурлыгын шарт итеп куя. Мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББСнда күрсәтелгән максат ориентирларын баланың ирешергә мөмкин булган казанышларының социаль-норматив сыйфатламалары буларак карарга кирәк. Бу — педагоглар һәм ата-аналар өчен өлкәннәрнең тәрбия эшчәнлегенең юнәлешен билгеләүче ориентир.

**Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы**

МББ ФДББС белән ярашлы рәвештә максат ориентирлары турыдан-туры, шул исәптән педагогик диагностика (мониторинг) рәвешендә дә, бәяләүгә алынмый һәм аларны балаларның реаль казанышлары белән формаль чагыштыру өчен нигез була алмый. Алар балаларның әзерлегенә һәм белем бирү эшчәнлегенә карата кабул ителгән таләпләргә туры килә торган объектив бәяләмәнең асылы булып тормый. Программаны үзләштерү арадаш аттестацияләр һәм тәрбияләнүчеләрнең йомгаклау аттестациясен уздыру белән кушылып китми.

Әмма педагог үз эше барышында һәрбер баланың индивидуаль үсеш траекториясен булдырырга тиеш. Моның өчен педагогка үз эшен бәяләүнең балалар белән иң уңайлы рәвештә үзара бәйләнеш булдырырга ярдәм итүче инструментарие кирәк.

Беренче чиратта, игътибарны әкренләп объектив (тестлар уздыру) якын килүдән аутентик бәяләү ягына күчерү турында сүз бара. Тамырлары белән стандартлаштырылган тест традицияләренә китеп, объектив якын килү кысаларында тикшеренүләр махсус бурычларны хәл итү барышында балалардагы аерымлыкларны (еш кына җитешсезлекләрне) билгеләүгә юнәлтелгән иде. Әлеге тестлар килеп чыккан нәтиҗәләрне

норма белән чагыштырырга мөмкинлек тудыра, шуның белән һәрбер баланың үз яшьтәшләре белән чагыштырганда үсеше турында мәгълүмат бирә. Шунлыктан мондый тестлар педагогик хәвефлелек төркеменә керергә тиешле балаларны ачыклауда киң кулланыла.

Әлеге ысулның төп җитешсезлеге шунда: ясалма биремнәр еш кына балаларның көндәлек тормышыннан шактый ерак, шуңа күрә алар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль мөмкинлекләрен тулысынча чагылдыра алмыйлар. Тест ысулы балаларның социаль даирәсе үзенчәлекләрен исәпкә алмый, һәм аның нәтиҗәләренә корылган фаразлар да шактый шартлы. Аутентик бәяләүнең нигезендә түбәндәге принциплар ята.

Беренчедән, асылда ул махсус биремнәрне үтәү нәтиҗәсенә түгел, баланың реаль тәртибен анализлауга карап корыла. Мәгълүмат турыдан-туры баланың тәртибен күзәтү ярдәмендә туплана. Күзәтү нәтиҗәләрен педагог гадәти тестларда куллана торган, мәктәпкәчә яшьтәге баланың реаль тормышына кагылышы аз булган уйлап чыгарылган ситуацияләрдә түгел, табигый мохиттә (уеннар вакытында, режим моментлары барышында, дәресләрдә) таба.

Икенчедән, әгәр тестларны махсус өйрәтелгән профессиональ белгечләр (психологлар, медицина хезмәткәрләре һ.б.) уздырса, аутентик бәяне исә бала белән озак вакыт булган, аның тәртибен яхшы белгән өлкәннәр куя ала. Бу очракта педагог тәҗрибәсе бәяләп бетергесез.

Өченчедән, аутентик бәя югары дәрәҗәдә структурлашкан.

Ниһаять, әгәр тестлар ярдәмендә бәя кую очрагында ата-аналар алынган мәгълүматларның мәгънәсен һәрвакытта да аңлап бетермәсәләр һәм шуңа да еш кына балаларга тест уздыруга тискәре мөнәсәбәт күрсәтсәләр, аутентик бәяләү вакытында җаваплар аларга аңлаешлы. Ата- аналар теге яисә бу сорауга җавап эзләгәндә педагогның партнерлары булып китәргә мөмкин.

## Педагогик диагностика

Программаны гамәлгә ашыру балаларның индивидуаль үсешен бәяләүне күздә тота. Мондый бәяләү педагогик хезмәткәр тарафыннан педагогик диагностика (мәктәпкәчә яшьтәге балаларның индивидуаль үсешенә педагогик гамәлләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү белән бәйле һәм аларны алга таба планлаштыруның нигезендә ятучы бәя бирү) кысаларында уздырыла. Педагогик диагностика балаларның гадәти һәм махсус оештырылган эшчәнлектә активлыгын күзәтү барышында үткәрелә. Педагогик диагностика өчен инструментарий — балалар үсешен күзәтү карталары, алар һәрбер баланың индивидуаль динамикасын һәм үсеш перспективаларын түбәндәгеләр барышында билгеләргә мөмкинлек бирә:

• яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашулар (контакт урнаштыру һәм аны дәвам итү, уртак карарлар кабул итү, каршылыкларны хәл итү, лидерлык һ.б. ысуллары ничек үзгәрә);
• уен эшчәнлеге;
• танып белү эшчәнлеге (балаларның сәләтләре, танып белү активлыгы үсеше ничек бара);
• проект эшчәнлеге (балаларның инициативалылыгы, җаваплылыгы һәм автономиясе үсеше ничек бара, үз эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру күнекмәсе ничек үсә);
• сәнгати эшчәнлек;
• физик эшчәнлек.

Педагогик диагностика нәтиҗәләре фәкать түбәндәге белем бирү бурычларын хәл итү өчен кулланыла ала:

1) белем бирүне индивидуальләштерү (шул исәптән балага булышлык күрсәтү, аның белем бирү траекториясен булдыру яисә аның үсеш үзенчәлекләренә профессиональ төзәтмә кертү);

2) балалар төркеме белән эшне оптимальләштерү. Белем бирү эшчәнлеге барышында балаларның индивидуаль динамикасын бәяләү һәм үз гамәлләренә төзәтмә кертү өчен педагоглар диагностик ситуацияләр булдырырга тиеш.

### 1.5 Беренче кечкенәләр төркеме эшчәнлегенең юнәлеше

Төркемдә белем бирү процессы комплекслы һәм яңа парциаль программалары кулланылып үткәрелә:

Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге «Туганнан алып мәктәпкәчә» төп белем бирү программасы. Программа сөйләм телен үстерү бүлегеннән тыш тулы күләмдә кулланыла.

*<u>Парциаль программа:</u>*

Р.К.Шәехова. «Сөенеч - Радость познания» региональ мәктәпкәчә белем бирү программасы, (ФДББС туры китерелгән).

## 2. Эчтәлек бүлеге

### 2.1. Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары

Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларның сыйфатлы физик үсешен тәэмин итү. Һәр баланың эмоциональ уңай халәтен саклауга булышу.

Үз вакытында гомуми хәрәкәтләр һәм кул хәрәкәтләре формалашуга, шуышырга һәм йөрергә өйрәнүгә ярдәм итү.

Баланың талчыгуын булдырмау.

Күрү һәм ишетү юнәлешләрен формалаштыру.

Сиземләү тәҗрибәсен баету.

Өлкән кешенең сүзләрен аңлау сәләтен үстерү һәм актив сөйләмгә ирешүгә әзерләү.

Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү процессына керешү омтылышларын хуплау.

Балаларның үзара татулыгына, якын кешеләренә карата аерым дустанә мөнәсәбәтенә булышлык итү.

Уенчыкларга, рәсемнәргә, музыкага, җырлауга карата кызыксыну уяту; баланың гади бию хәрәкәтләре башкарудагы активлыгына булышлык итү.

Һәр баланың үз яшенә туры килгән сәләтләрне үзләштерүенә актив ярдәм итү, алынган нәтиҗәләрне системалы рәвештә һәм дөрес анализлау.

### 2.2. 2 яшьтән алып мәктәп яшенә кадәрге балаларның үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирү эшчәнлеге

2–7 яшьлек балалар белән психологик-педагогик эш эчтәлеге «Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгати- эстетик үсеш», «Физик үсеш» белем бирү өлкәләре буенча бирелә. Эшнең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, аларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып, төрле яклап үсешенә юнәлтелгән. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатларын формалаштыру буенча психологик-педагогик эш бурычлары белем бирүнең һәрбер өлкәсенең үзгәлеген чагылдыра торган бурычлар белән, мәҗбүри психологик тәэмин итү белән беррәттән, барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү барышында интеграцияле хәл ителә. Бу очракта программаның мәгариф бурычларын хәл итү турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, режимлы моментлар барышында да — өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә дә, мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең мөстәкыйль эшчәнлегендә дә карала.

## 2.3 Белем өлкәләре буенча комплеклы - тематик план
## 2.3.1. «СОЦИАЛЬ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ» белем бирү өлкәсе

### *Социальләштерү*

***Аңлатма язуы***

«Социальләштерү» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Туган телдә аралашырга теләкләрен хуплау; башка кешеләр белән аралашканда, аларның тәкъдимнәренә әдәпле итеп җавап бирү; төрле эшчәнлек төрләрендә өлкәннәр һәм балалар белән телдән һәм телдән булмаган бәйләнешләр урнаштыру.

Әйләнә-тирә, туган шәһәр (авыл), республика вакыйгалары турында әңгәмәләрне хуплау.

Аралашу культурасы формалаштыру (сөйләшүченең милләтенә карап, ачык йөз күрсәтеп, шул телдә исәнләшү һәм саубуллашу; үтенеч һәм тәкъдимнәр белән ягымлы итеп мөрәҗәгать итү; күрсәткән хезмәте, ярдәме, сый-хөрмәте өчен рәхмәт белдерү).

Балаларны ил, республиканың күренекле төп бәйрәмнәрен билгеләп үтәргә өйрәтү. Балалар оешмасы, республика, ил тормышына баланың мөнәсәбәте, катнашы булуын аңлавына ирешү.

Өлкәннәр һәм яшьтәшләре (өч-дүрт бала) белән күмәк уеннарда катнашуга теләк уяту; әйләнә-тирәдәге тормыш, халыклар яшәеше темасына татар язучылары һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләре, мультфильмнар буенча, уен өчен катлаулы булмаган сюжетлар тәкъдим итү.

Уендагы иптәшләр арасында рольләрне бүлә белергә, уен өчен кирәкле өй кирәк-ярагы (көянтә-чиләкләр, казан, уклау һ. б.), милли костюм, ювелир (зәркән) бизәнү әйберләре, читекләр һ. б., милли уенчыклар, музыка уен кораллары сайларга һәм аларны рольгә туры китереп файдаланырга өйрәтү.

Милли киемдәге курчакларны, образлы уенчыкларны, бибабо, кулдан ясалган уенчыклар һәм кайбер сәнгатьлелек чараларын, кул хәрәкәтләре, мимика, интонация кулланып, театральләштерелгән һәм режиссер уеннарында катлаулы булмаган сюжетлар буенча (татар халык әкиятләре буенча куелган мультфильмнардан) ситуацияләрне уйнап күрсәтү.

Баланың үзе, әти-әниләренең милләте турындагы күзаллавын формалаштыру. Гаилә рәсемнәрен караганда, әти-әниләре белән охшаш чалымнары булуына игътибар итү. Фото- сурәттәге кешеләрнең эмоциональ халәтен билгеләргә, аларның кәефләрен гаилә тормышындагы билгеле бер вакыйга белән бәйләргә өйрәтү.Гаилә турында һәм үзенең шул гаилә әгъзасы булуы турында; гаиләнең барлык әгъзаларының һәм баланың үзенең бурычлары, мавыгулары, яллары турында; гаилә гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәренең матурлыгы һәм әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә истәлекләренә сакчыл караш тәрбияләү.

***Сюжетлы – рольле уеннар***
***Комплекслы – тематик план***

| **Ай** | **атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Эшчәнлек эчтәлеге** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Гаилә | Әни кызы белән бергәләп ашарга әзерли, кызын ашата. Д/уен «Ашарга пешерәбез», «Курчакны сыйлыйбыз». | Балаларны уен атрибутлары, гаиләдә башкарыла торган эш-гамәлләр, уен почмаклары белән таныштыру, диалогик сөйләм күнекмәләре бирү,татарча сөйләшергә өйр.Уенчык исемнәрен әйтергә өйрәтү, форма,төс,зурлыкларын чагыштыру, һәр уенчыкның үз урыны барлыгын белү һәм истә калдырырга өйрәтү. Балаларны шөгыль вакытында үзләрен тыныч тотарга, тыңларга, игътибар туплый белергә,рәсем ясарга һәм әвәләргә өйрәтү.Йокының сәламәтлек өчен файдасын аңлату, йоклау әдәбенә, культурасына өйрәтү, бишек җырлары белән танышу. Машиналарга сак караш, шофёр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү, машины өлеш-кисәкләре,төсләре, зурлыклары буенча аерырга өйрәтү. Кизү тору эше,өстәл әзерләү тәртибе, ризык һәм савыт-саба исемнәре белән танышу. Кунак каршылау, сыйлау әдәбе белән танышу. |
| | | Балалар бакчасы | Балалар бакчага киләләр, уйныйлар,шөгыльләнәләр,рәсемнәр ясыйлар, китап карыйлар һ.б. . | |
| | II | Уенчыклар кибете | Балалар уенчыклар белән танышалар,исемнәрен әйтергә өйрәтү, төсләрен карыйлар,бер-берсеннән аерырга өйрәнәләр. | |
| | | Гаилә | Әни кызын юындыра,әкият укый,бишек җыры көйләп йокларга яткыра.Д/у-р: “Курчакны юындыру”,”Курчакны йоклату” | |
| | III | Уенчыклар кибете | Әни кызы белән кибеткә килә, уенчыклар ала. Сатучы товар сата.Д/уен “Уенчыклар кибетендә ниләр сатыла?”. | |
| | | Балалар бакчасы | Балалар физкультура белән шөгыльләнәләр, иртәнге гимнастика ясыйлар, җырларга һәм биергә өйрәнәләр. Д/уен”Без шөгыльдә” | |
| | IV | Гаилә | Әни кызы белән бергәләп рәсем ясый, пластилиннан төрле әйберләр ясый. Д/у”Курчакны рәсем ясарга һәм әвәләргә өйрәтү” | |
| | | Яшелчәләр кибете | Әни кызы белән кибеткә килә, яшелчә сорап ала, “тылсымлы” сүзләр кулланырга өйрәтү, диалогик сөйләм күнекмәсен үстерү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| октябрь | I | Гаилә | Әни юа, кием үтүкли, бүлмә җыештыра. Д/уен «Курчакның күлмәген үтүклик, бездә тәртип» | Балаларны уен атрибутлары, гаиләдә башкарыла торган эш-гамәлләр, уен почмаклары белән таныштыру, диалогик сөйләм күнекмәләре бирү,татарча сөйләшергә өйрәтү. Уенчык исемнәрен әйтергә өйрәтү, форма, төс, зурлыкларын чагыштыру, һәр уенчыкның үз урыны барлыгын белү һәм истә калдырырга өйрәтү. |
| | II | Балалар бакчасы | Балалар бакчага килә, арыгач йоклап ял итеп алалар, йоклаганда үсәләр.Д/у"Алсуны йоклату". | |
| | III | Гаилә | Әни кызын ашата, йокларга яткыра, бишек җырлары җырлый. | |
| | IV | Гараж | Машиналар гараждан чыгып китеп төрле эш башкаралар. Башкару хезмәте буенча маш.-ны йөк яки кешеләр утырып йөри торган машина итеп уйнау.Машинаның өлеш-кисәкләре, шофёр һөнәре белән танышу.Уен беткәч машиналар барысы да гаражга кайта, "ремонтлана." | |
| ноябрь | I | Без төзүчеләр | Төзүчеләр машиналарга гаражлар, җәнлекләргә йортлар, курчаклар өчен йокы, аш-су бүлмәләре төзиләр, төзелеш материаллары белән танышалар, исемнәрен әйтергә өйрәнәләр. | Балаларны шөгыль вакытында үзләрен тыныч тотарга, тыңларга, игътибар туплый белергә,рәсем ясарга һәм әвәләргә өйрәтү.Йокының сәламәтлек өчен файдасын аңлату, йоклау әдәбенә, культурасына өйрәтү, бишек җырлары белән танышу, төзелеш материаллары белән таныштыру, исемнәрен әйтергә өйрәтү. |
| | II | Гаилә | Әни аш өстәле әзерли, кызы булыша: өстәлгә тәлинкәләр куя, салфеткалар җәя,кашыклар куя h. б..<br>Д/ у"Аш өстәле әзерлибез". | |
| | III | Чәчтараш | Чәчтарашка балалар әниләре белән киләләр. Парикмахер чәч тарый һәм ала. Дидактик уен "Чәчтараш җиһазлары". | |
| | IV | Гаилә | Курчакның туган көне. Кунаклар чакырабыз, сыйлыйбыз. Кунаклар янында үзеңне әдәпле тота белергә өйрәтү. | |
| декабрь | I | Кафе | Кафега киләләр, алар туңдырма ашыйлар, сок эчәләр. Официант заказ кабул итә һәм сораган әйберләрне китерә.<br>Дидактик уен «Без кафега килдек». | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга, иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга өндәү, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | II | Поликлиника | Медсестра прививка ясый, витаминнар тәкъдим итә.<br>Шәфкать туташы эшен күзәтү. | |
| | III | Бүген бәйрәм! | Балалар шәһәр буйлап экскурсиягә чыгалар, бәйрәмчә бизәлгән урамны карыйлар. Рәсемнәр карау. Балаларда шатлана белү хисләре тәрбияләү. | Җәмгыять урыннарында үзеңне тота белү кагыйдәсе белән танышуны дәвам итү,үзара дус уйный белү күнекмәсе тәрбияләү. Күңелсез хәлләргә юлыккан |
| | IV | Гаилә | Әни кызы белән чыршы бизи, уенчыкларның исемнәре, формалары, төсләре белән таныша, Яңа ел бәйрәме турында күзаллавы баетыла. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Уку: Ә. Бикчурин. “Чыршы” шигыре.Дидактик уен «Акбайга кунаклар каршы алуны күрсәтик» | вакытта каушап калмаска,үзеңне тыныч тотып, ярдәмгә ашыгырга кирәк икәнен аңлату. |
| январь | I | Чәчтараш | Чәчтарашка балалар әниләре белән киләләр. Парикмахер чәч тарый һәм ала. Дидактик уен “Чәчтараш җиһазлары” | Җәмгыять урыннарында үзеңне тота белү кагыйдәсе белән танышуны дәвам итү,үзара дус уйный белү күнекмәсе тәрбияләү. Күңелсез хәлләргә юлыккан вакытта каушап калмаска,үзеңне тыныч тотып, ярдәмгә ашыгырга кирәк икәнен аңлату. |
| | II | Шифаханә | Кызы авыргач әнисе аны поликлиникага алып бара, врачка күрсәтә. Әңгәмә «Әгәр берәрсе авырса нишләргә?” | |
| | III | Театр | Балалар театрга баралар, билетлар алалар, театр күрсәтәләр. Әңгәмә “Театр төрләре” | |
| | IV | Транспорт | Кунакка поездда баралар. Пассажирлар билет сатып алалар. Рәсемнәр карау. | |
| февраль | I | Гаилә | Курчакларны киендереп урамга чыгалар. Урамда балалар белән коляска йөртүче әниләрне күзәтәләр.<br>Дид/уен «Курчакны йөртәбез» | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү, һөнәр кирәк-яраклары турындагы белемнәрен, диалог корып сөйләшә белү күнекмәләрен үстерү. |
| | II | Коткару хезмәте | Коткару хезмәте кешеләре авыр очракларда ярдәмгә ашыгалар: пожар, юлларда хәләкәт, җир тетрәү. | |
| | III | Машинаны төзәтәбез | Машиналарны төзәтүче янына алып киләләр, төзәтүче машиналарны карый, төзәтә. | |
| | IV | Автобус | Балалар автобус тукталышында торалар, автобуска утыралар, билет алалар. Әңгәмә “Җәмгыять транспортында үзеңне тоту кагыйдәләре”. | |
| март | I | Мин сатучы | Әни кызы белән кибеткә килә, бәйрәмгә азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә үлчи. Әңгәмә “Сатучы һөнәре” | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү.<br>Балаларның дуслык турында мәгълүматларын тулыландыру, әләкләшүнең начар гадәт икәненә, дусларыңны уңайсыз хәлгә куярга ярамаганлыгына төшендерү.<br>Балаларның үзаңын үстерергә булышу, төзелеш барган урыннарга якын килеп уйнарга ярамаганын аңлату, куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | II | Гаилә | 8март бәйрәме: бүләкләр алу, үз кулларың белән әниләргә, әбиләргә бүләкләр ясау, өстәлне бәйрәмгә әзерләү.“Ләйлә” шигырен уку, “Минем әнием” әңгәмә. | |
| | III | Гаилә | Курчакның киемнәрен юалар, үтеклиләр, киптерергә эләләр. Әңгәмә “Кием төрләре” | |
| | IV | Цирк | Балалар циркка баралар, билетлар алалар, клоуннар тамаша күрсәтә. | |
| ап | I | Янгын | Янгын сүндерүчеләр чакыруга килә, янгын сүндерә, беренче ярдәм | Җәмгыять урыннарында үзеңне |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | сүндерү-челәр | күрсәтә, кисәтә. Дидактик уен “Ут сүндерүчеләр әлифбасы”, “Ут белән уйнама!”. Уку С. Маршак «Песи өендә янгын », «Янгын ». | тота белү кагыйдәсе белән танышуны дәвам итү,үзара дус уйный белү күнекмәсе тәрбияләү. Күңелсез хәлләргә юлыккан вакытта каушап калмаска,үзеңне тыныч тотып, ярдәмгә ашыгырга кирәк икәнен аңлату. |
| | II | Почта | Кешеләр бер-берсенә хатлар язалар, телеграмма, посылка җибәрәләр. Почта ташучы аларны адреслар буенча тапшыра. Почтадан җибәрелгән әйберләрнең рәсемнәрен карау. Дидактик уеннар һәм күнегүләр: «Дустыма хат», «Минем адрес». | |
| | III | Телефон салоны | Балалар телефон салонына киләләр, телефоннар һәм фотоаппаратлар карыйлар, сатып алалар. Әңгәмә “Телефон ни өчен кирәк?” | |
| | IV | Төзелеш | Төзүчеләр киләләр, төзелеш өчен план алалар, күп машиналар өчен зур гараж, өйләр төзиләр, төзелеш объектларын тапшыралар.Рәсемнәр карау. Якын тирәдәге объектларны күзәтү. | |
| май | I | Уенчыклар кибете | Сатып алучылар уенчык сайлыйлар, сатучы белән киңәшәләр, кассага акча түлиләр, чекларны сатучыга бирәләр. Сатучы сатып алучылар белән әдәпле итеп сөйләшә, аларга төрле уенчыклар тәкъдим итә. Әңгәмә “Әдәпле сатып алучылар”. Дидактик уен: «Уенчыкны тасвирла!», «Нәрсә үзгәрде?», «Тасвирлау буенча тап!». | |
| | II | Гаилә | Җиңү бәйрәме: бүләкләр алу, үз кулларың белән бабайларга, әбиләргә бүләкләр ясау, өстәлне бәйрәмгә әзерләү. Әңгәмә “Җиңү бәйрәме” | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү, һәнәр кирәк-яраклары турындагы белемнәрен, диалог корып сөйләшә белү күнекмәләрен үстерү. |
| | III | Транспорт | Йөк һәм җиңел машиналар урамда йөри, җәяүлеләр тротуардан баралар, җәяүле чыгу урыныннан юл аркылы чыгалар, бетенесе дә юл йөрү кагыйдәләрен үтиләр.Светофорга, көйләнелми торган юл чатына максатлы сәяхәт.Дидактик уен: «Игътибар, җәяүле!», «Кызыл, сары, яшел» | |
| | IV | Кибет | Төрле бүлекләре (табак-савыт, йорт җиһазлары, язу-сызу әйберләре һ.б.) булган яңа супермаркет ачылды. Сатып алучылар әйбер сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар (төсе, материалы, кулланылышы). | |

## *Хезмәт*

### *Аңлатма язуы*

«Хезмәт» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар халык әкиятләре ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллаулар формалаштыру. Баланың эш барышын татар шагыйрьләренең хезмәт турындагы шигырьләре белән бәйләү.

Балаларга аңлаешлы һөнәрләр (төзүче, электрик, сантехник һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлегенең мәгънәсе турында күзаллаулар формалаштыру. Хезмәт эшчәнлегенең төп бурычы булып тора. Бу бурычны тормышка ашыру түбәндәге мәсьәләләрне чишү аша башкарыла:

- зурлар хезмәте белән танышу, хезмәтнең җәмгыятькә кирәклеге һәм файдасы турында күзаллауларын формалаштыру һәм кеше хезмәтенә хөрмәт, хезмәтнең нәтиҗәсенә сак караш тәрбияләү;
- балаларның хезмәт эшчәнлеген оештыру, эш тәҗрибәсе , эшне оештыру, зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара уңай мөнәсәбәтләр урнаштыру күнекмәләрен камилләштерү.

### *Комплекслы-тематик план*

| Тема | Интеграция |
|---|---|
| ***Сентябрь*** | |
| 1. Балалар бакчасы белән таныштыру, бакча шартларына ияләштерү.<br>2.Уенчыкларны, уен материалларын урыннарына куярга өйрәтү.<br>3.Өлкәннәр ярдәме белән киенү-чишенү күнекмәләрен үстерү, киемнәрне шкафка җыеп кую тәртибе белән танышу.<br>4. Шәхси әйберләр белән эш итәргә өйрәтү.<br>5. Мөстәкыйль хезмәт күрсәтү күнекмәсен үстерә бару. | **Җыр- бию**: Н.Гайсин сүзл.,Н.Зарипова муз.“Балалар бакчасында “җырын тыңлау, балалар бакчасы шартларына ияләштерүдә балаларда уңай эмоция булдыру.Җ.Тәрҗеманов ”Йомшак су,йөгерек су”- үз-үзенә хезмәт күрсәтү күнекмәсен үстерү.<br>**Аралашу**: иптәшләре, тәрбияче һәм тәрбияче ярдәмчесе белән танышу,исемнәрне әйтергә һәм истә калдырырга өйрәнү.<br>**Сәламәтлек**:шәхси-гигиена таләпләрен үтәү теләге тудыру.<br>**Танып белү**:уен бүлмәсе һәм андагы махсус почмаклар белән танышу |
| ***Октябрь*** | |
| 1.Үз-үзенә мөстәкыйль хезмәт күрсәтү күнекмәсен үстерү.<br>2. Өлкәннәр ярдәме белән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнүне дәвам итү.<br>3. Өлкәннәр ярдәме белән киенү-чишенү, киемнәрне шкафка җыеп кую тәртибе белән танышуны дәвам итү. | **Сәламәтлек**:үз – үзеңне һәрвакыт тәртиптә тотарга кирәклекне аңлату, шәхси гигиена таләпләрен үтәргә өйрәтү.<br>**Аралашу**:тәрбиячене һәм иптәшләрен тыңлый белергә өйрәнү.<br>**Танып белү**: балаларның ишетеп кабул итү, тыңлый белү осталыгын үстерү. |

| | |
|---|---|
| 4. Тәрбиячене҅ң бүлмә гөлләрен карау-тәрбияләвен күзәтү аша, балаларда үсемлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү, тәрбиячегә булышасы килү теләге уяту.<br>5.Культура- гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру. | **Матур әд.уку**: З.Туфайлова “Ул зур”, үскән гөлләргә карата сакчыл караш, матурлыкка соклану тәрбияләү. |
| ***Ноябрь*** | |
| 1. Өлкәннәр ярдәме белән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен өйрәнүне дәвам итү.<br>2.Үзлектән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнү.<br>3. Уйнаганнан соң уенчыкларны җыеп, урыннарына куярга өйрәнү, уенчыкларга сак караш тәрбияләү.<br>4.Тәрбиячене҅ң бүлмә гөлләрен каравын- тәрбияләвен күзәтү: су сибү, тузанын сөртү, төпләрен йомшарту. | **Матур әд.уку**: Ә.Бикч.”Туп-туп- тубыбыз”.Шигырь аша уенчыкларга сак караш тәрбияләргә өйрәнү.<br>**Аралашу**: бергәләп уйнау теләге тәрбиләү.<br>**Социальләштерү**: кушылган эшкә карата җаваплылык формалаштыру .<br>**Танып белү**: бүлмә гөлләрен карау, тәрбияләү хезмәте аша балаларны табигать дөньясына җәлеп итү, кызыксынучанлыкларын үстерү. |
| ***Декабрь*** | |
| 1. Өлкәннәр ярдәме белән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен үстерү.<br>2. Үзлектән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнүне дәвам итү.<br>3.Һавада уйнаганнан соң өс-баш киемнәрен кагарга, бер-берсенә ярдәм итәргә,үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәсен үстерергә өйрәнү.<br>4.Балаларның игътибарын ишегалдын җыештыручы хезмәтенә юнәлтү, балаларда бу төр хезмәт ияләренә хөрмәт, җыештыручыга булышасы килү теләге уяту. | **Аралашу**: балаларны үзара дус,тату булырга өндәү, тыныч сөйләшергә өйрәтү.<br>**Социальләштерү:** зурлар хезмәтенә хөрмәт,аларга ярдәм итәсе килү омтылышытәрб.<br>**Танып белү:** ишегалдын җыештыручы хезмәте б-нтанышу, кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштыру.<br>**Матур әд**.: Г.Тукай “Гали белән кәҗә” шигырен уку: бер-берсенә карата кайгыртучанлык тәрбиләү. |
| ***Январь*** | |
| 1. Балаларны һәрвакыт үзеңнең тышкы кыяфәтеңне карап торырга, үзлектән, булган җитешсезлекне бетерергә өйр.<br>2. Зурлар ярдәме белән киемнәрне тәртиптә тоту күнекмәләрен формалаштыру (чистарту, киптерү).<br>3. Үзлектән бер-берсенә һәм өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту.<br>4.Балаларның игътибарын тәрбияче ярдәмчесенең нәрсә эшләвенә, ул эш-гамәлне ничек һәм ни өчен башкаруына юнәлтү. | **Социальләштерү**:балаларда игътибарлылык,үз-үзеңә таләпчәнлек тәрбияләү.<br>**Аралашу**: балаларың бер-берсенә карата мөгалләмәсендә дуслык, хөрмәт, ярдәмчеллек хисләре тәрбиләү.<br>**Танып белү**: тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән танышу, балаларда тәрбияче ярдәмчесенә булышасы килү теләге тәрбияләү. |
| ***Февраль*** | |

| | |
|---|---|
| 1. Үзлектән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү.<br>2. Тәрб. ярд. күзәтчелеге астында ашау алдыннан өстәлгә ипи тәлинкәләрен һәм салфетка савытларын куярга өйрәтү.<br>3. Балаларда тәрбияченең табигать почмагындагы хезмәтен күзәтү даирәсен киңәйтү(суган,чәчәк орлыклары утырту).<br>4. Дидактик уен «Гөлләргә ни булган?<br>5. Рәсемнәр карап, әтиләр башкарган хезмәт белән танышу. | **Танып белү**:өлкәннәрнең табигатьпочмагындагы гөлләрне карау-тәрбияләүләрен күзәтү,үсү шартлары белән танышу.<br>**Социальләштерү:**с/р уен элементлары формалаштыра башлау, әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту,илдә барган бәйрәмнәр белән танышып бару.<br>**Аралашу**: балаларны өлкәннәргә булышырга өйрәтү, иң гади хезмәт эшчәнлегендә катнашырга омтылыш тәрбияләү. |
| ***Март*** | |
| 1. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Өлкәннәр ярдәме белән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен системалаштыруны дәвам итү.<br>3. Тәрбияченең белем эшчәнлегенә кирәк яраклар әзерләвен күзәтү, иң гади дежурлык вазыйфасын үтәү элементлары булдыруны дәвам итү.<br>4. Рәсемнәр карап, әниләр башкарган хезмәт белән танышу. | **Танып белү**: әниләр һөнәренә кагылышлы рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, төрле һөнәрләр белән танышу, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.<br>**Социальләштерү**: әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, әниләргә хөрмәт тәрбияләү, бәйрәмнәр белән танышу.<br>**Җыр тыңлау:** ”Рәхмәт әнием”Ә.Һадиева муз.,А. Минһаҗев сүзләре.<br>**Аралашу**: тәрбияче хезмәте белән кызыксыну, катлаулы булмаган биремнәрне үтәү осталыгына ирешү. |
| ***Апрель*** | |
| 1.Төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен мөстәкыйльләштерә бару, башлаган эшне ахырына кадәр эшләргә өйрәнү.<br>2. Балалар бакчасы уен җирлегендә иң гади хезмәт эшчәнлегендә катнашырга омтылыш тәрбияләү: кипкән яфраклар,чыбык-чабыклар җыярга теләк белдерү, тәрбиячегә булышу.<br>3. Уен өчен кирәкле әйберләрне урамга алып чыгуда һәм ахырдан җыеп алып керүдә тәрбиячегә булышырга өйрәнү, балаларда хезмәткә җаваплы караш тәрбияләү.<br>4.С/р уеннар: “Сатучы”,”Чәчтараш”,”Пешекче”аша бу төр төр хезмәт ияләренең хезмәте белән танышу, эшкә җаваплы караш тәрбияләү. | **Аралашу**: балаларның зурлар һәм иптәшләре белән ирекле аралашуларына ирешү.<br>**Танып белү**: үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен һәм файдасын күрә белергә өйрәнү, гади хезмәт хәрәкәтләрен теләп башкарырга өйрәтү, эш кораллары белән танышу.<br>**Социальләштерү**: табигатьтә яз көне башкарыла торган хезмәт белән танышу. |
| ***Май*** | |
| 1. Үз үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Утырткан үсемлекләрне тәрбияләүгә кызыксынучанлык, хезмәткә | **Танып белү**: үсемлекләрнең үсешен күзәтү, үсү шартлары бедән кызыксыну. |

| | |
|---|---|
| булышасы килү теләге тәрбияләүне дәвам итү.<br>3. Зурлар хезмәте турында ( шофер, очучы, табиб, һ.б.) күзаллау булдыру.<br>4. Сюжетлы-рольле уеннар “Шофер”, “Шифаханә”, “Очучы” | **Социальләштерү:** Һөнәр ияләре турында рәсемнәр карау, тәрбияче ярдәме белән уеннарны рольләргә бүлергә өйрәнү.<br>**Җыр тыңлау**: “Мин шофёр” |

***Куркынычсызлык***

***Аңлатма язуы***

«Куркынычсызлык» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

***Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру***

Балаларны балалар бакчасында көндәлек режим һәм үз- үзләрен тотуның иң элементар кагыйдәләре белән, бүлмәдә хәвеф-хәтәрсез йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Үз тормышың куркынычсызлыгы нигезләре турында белемнәрне үзләштерү, саклык, сизгерлек хисе тәрбияләү.

Балаларны тормышта яңа, алар өчен гадәти булмаган очракларда, таныш булмаган кешеләр белән очрашканда үз- үзләрен дөрес тотарга өйрәтү.

***Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру***

Юл хәрәкәтендә светофорның кызыл, сары, яшел төсләренең урнашу тәртибе һәм мәгънәләре белән таныштыру. Светофор сигналы буенча хәрәкәт итәргә күнектерү.

Балаларны юнәлешләрне (алга - артка, өскә - аска, уңга - сулга) аерырга гына түгел, шулай ук күрсәтелгән юнәлештә йөрергә, үзеңә карата теге яки бу әйбернең торышын (миннән сул якта - өй, уңда - машина, алда - җәяүлеләр, артта - велосипедчы) билгеләргә өйрәтү.

Чагыштырмача хәрәкәт итү тизлеген (тиз, акрын) билгеләргә, транспорт чараларының (трамвай, автобус, янгын сүндерү машинасы, ашыгыч ярдәм машинасы һ. б.ның) тавыш сигналларын аерырга, тавыш чыганагының кайда булуын сиземләргә, кирәк очракта туктарга өйрәтү. Ишетү-хәрәкәт координациясен үстерү.

Кайбер җәмәгать транспортлары (троллейбус, автобус, трамвай, поезд, самолёт, теплоход һ. б.) турында күзаллауларны баету; маршрут транспорты (автобус, троллейбус, трамвай) тукталышы урыннарын билгеләү; «Автобус яки троллейбус тукталышы»н аңлатучы билге белән таныштыру. Җәмәгать транспортына утыру һәм аннан чыгу кагыйдәләренә игътибар итү.

Балаларга метрополитен, тимер юл, поезд, машинист хезмәте, тимер юлда һәм тимер юл транспортында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләү. Тимер юл макеты белән таныштыру.

Урамда үз-үзеңне тотуның иң элементар кагыйдәләрен (йөгермәү, кычкырмау, тротуар кырыеннан йөрмәү һ. б.) үтәүгә ирешү. Җәяүле юлы белән, «җәяүлеләр юлы» билгесе белән таныштыру; урамны кайда һәм ничек аркылы чыгу турында, велосипедта йөрү кагыйдәләре турында аңлату.

Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буенча, предметларны әйләнеп үтеп, өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәтүне дәвам итү. Үз хәрәкәтләре белән идарә итә белү, тормозга басып туктата алу күнекмәләрен үстерү. Спорт мәйданчыгында иркен ориентлаша белүне камилләштерү.

Транспорт чараларының охшаш һәм аермалы якларын табарга, билгеләнгән үзлекләре һәм функциональ үзенчәлекләре буенча

чагыштырырга һәм төркемнәргә берләштерергә өйрәтү, алынган мәгълүматны гомумиләштерергә тырышуларын («Охшашны җый», «Оча, йөзә, йөри» һ. б.) хуплау.

Өлкәннәр хезмәте турындагы белемнәрен киңәйтү: троллейбус (автобус) йөртүче троллейбус (автобус) йөртә; кар җыйгыч машинаны йөртүче юлларны кардан чистарта; ЮХИДИ инспекторы юлларда автомобильләр хәрәкәтен җайга сала һ. б.; эш төрләре һәм эш максаты арасында бәйләнешне ачыкларга ярдәм итү.

Балаларның, сюжетлы-рольле уенда юлда имин йөрү кагыйдәләрен чагылдыру өчен, мөстәкыйль рәвештә пред- метлы-уенлы мохит тудыруларын, модульләргә уен мәгънәсе бирүләрен, образлы һәм техник уенчыкларны, аларны алыштыручы алмаш предметларны куллануларын хуплау.

Балаларны уен ситуацияләрендә шартлы уйдырманың максатын аңларга, коллективта уен кагыйдәләренә яраклашып эш итәргә, игътибарлы булырга, уен персонажларының (транспорт йөртүчеләр, җәяүлеләр, пассажирлар һ. б.) роль буенча хәрәкәтләрен төгәлрәк башкарырга, ишетү һәм күрү сигналларына, әйләнә-тирәдәге көтелмәгән үзгәрешләргә тиз җавап бирергә, мөстәкыйльлек күрсәтергә һәм мәйданда ориентлашырга өйрәтү.

Мөстәкыйль дидактик уеннарда балаларның алган тәҗрибәләрен файдалануга шартлар тудыру. Төрле характердагы ял итү уеннары оештыру; юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен әһәмиятле ситуацияләрне эченә алган уен-мавыгулар, курчак театры, сәхнәләштерелгән гади әсәрләр, уеннар өйрәнү.

Балаларда, шартлар буенча һәм үзләре уйлап тапканча, шәһәр (авыл) урамнары макетын төзү теләкләрен үстерү. Балаларны объектларның пространстводагы сурәтләмәләрен - озынлыкларын (биеклекләр, киңлекләрен) аера белү; деталь һәм аның өлешләренең урынын (өстән, астан, өстенә, астына һ. б.) билгеләүгә; объектларны (деталь һәм аның өлешләрен һ. б.ны) анализларга өйрәтү; тимер юллар, ике яклы хәрәкәт итү юллары, күперләр, гаражлар һ. б.төзүгә омтылышларын үстерү.

Балаларны табигать күренешләренә, тәүлектәге үзгәрешләргә һәм аларның әйләнә-тирәдә чагылышына (кич - урамда караңгы төшә - багана башларында фонарьлар яна, машиналар фараларын кабыза) игътибар итәргә өйрәтү.

Юлларда куркынычсыз йөрү кагыйдәләрен өйрәнү процессына кызыксыну уяту.

***Экологик аң алшартларын формалаштыру***

Балаларны хайваннар белән очрашканда сак булырга өйрәтү, агулы үсемлекләрнең үзлекләре турында кисәтү.

Кайбер куркыныч сыеклыклар, газсыман матдәләр, ут, зарарлы ашамлыклар турында, витаминнар, дару препаратларын күп күләмдә кабул итүнең куркынычлыгы турындагы күзаллауларын үстерү.

***Комплекслы - тематик план***

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар | Интеграция |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Уен мәйданчыгы белән танышу | Уен мәйданчыгыннан читкә китәргә ярамаганлыкны аңлату | **Иҗади сәнгать**: рәсем яки ябыштыру «Светофор».<br>*Уку*: А. Усачев «Домик у перехода» (ятлау) |
| | II | Урам белән танышу. (картинадагы рәсем | Урам турында күзаллау булдыру | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | аша) | | *Социаль – коммуникатив үсеш*: фикер йөртү: «Берүзем өйдә», «Берүзем урамда», рәсемнәр буенча кечкенә хикәя төзү. *Физик культура*: хәрәкәтле уен «Төсле автомобильләр **Соц.-комм. үсеш**: Транспорт төрләре турында картина карау. **Җыр тыңлау**:"Светофор" |
| | III | Урамдагы машиналар | Машиналарның башкару хезмәтенә карап күп төрле булуына игътибар итү, аларның юллары аерым булуын аңлату. | |
| | IV | Светофор рәсемен карау | Светофорның ни өчен кирәклеген аңлату | |
| Октябрь | I | Җәяүлеләр юлы(рәсем карау) | Урамдагы җәяүлеләрнең тротуардан гына йөрергә тиешлеген аңлату | **Танып белү:**урам күренешесурәтләнгән картина карау**.** **Социаль-коммуникатив үсеш**: урам, урамдагы машиналар, машина юлы һәм тротуар белән танышу. **Физкультура:** Х/уен-р:"Без шофёрлар", "Светофор һәм машиналар" |
| | II | Урам аша ничек чыгарга? | Урам аша чыкканда зурларның кулына тотынырга кирәклекне аңлату. | |
| | III | Светофорда кызыл ут яна | Кызыл утның нәрсә аңлатканы белән танышу | |
| | IV | Светофорда сары ут | Сары төснең "Көтеп тор!" һәм "Әзерлән!"дигән сигнал булуын аңлату | |
| ноябрь | I | Светофорның яшел уты | Юл аша яшел ут янгач кына чыгарга мөмкин икәнен аңлату. | **Физкультура**.Х/уен"Без кунакка барабыз". **Танып белү**. Картина карау. Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү: урамда кычкырма!, юлга якын җирдә уйнама!, тротуарның юлга якын җиреннән барма! **Иҗат**.Пластилиннан шарлар тәгәрәтеп һәм картон өслеккә ябыштырып светофор ясау |
| | II | Юл йөрү кагыйдәләре | Балаларга юлда йөрүнең үз тәртибе, кагыйдәсе булуын, аны һәр кешедә сакларга тиешлекне аңлату. | |
| | III | Тротуардан ничек йөрергә? | Тротуарның машина юлына якын җиреннән йөрергә ярамаганлыкны аңлату. | |
| | IV | Светофор-<br>ның өч төсе | Светофор төсләренең нәрсә аңлатканын ныгыту | |
| декабрь | I | Электр лампасы белән танышу | Ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү. | **Танып белү**.Электр турында б-га гади төшенчә бирү,сакчыллык тәрбияләү. **Танып белү**.Электр приборлары |
| | II | Электр приборлары | Электр приборларына зурлардан башка тотынырга ярамаганлыкны аңлату. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | III | Янгын нәрсәдән чыгарга мөмкин? | Балаларны,картинада сурәтләнгән рәсемнәр аша, янгын килеп чыгардай эш-гамәлләр белән таныштыру: зурлардан башка электр приборларына, шырпыга, ут кабызгычларга кагылырга ярамый. | сурәтләнгән рәсемнәр карау.<br>**Матур әдәбият**”Песи өендә янгын” шигырен уку.<br>**Социальләштерү.** Янгын сүндерүчеләр рәсемен карау |
| | IV | Кемнәр алар янгын сүндерүчеләр? | Бу төр һөнәр ияләренең нинди авыр хезмәт башкаруларын балалар аңына җиткерергә тырышу. | |
| январь | I | «Сак бул, бозлавык!». | Кышкы юлның үзенчәлекләре белән таныштыру, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне булдыру. | **Танып белү**: Тайгак юлда машиналарга йөрергә бик авырбулуын, тротуарның юлга якын җиреннән барсаң, куркыныч хәлгә юлыгырга мөмкин икәнен аңлату.<br>**Социальләштерү:** “Бәхетсезлек очракларыннан ничек сакланырга?”дигән рәсемнәр җыелмасы карау.<br>**Танып белү.**Агач-куакларның ботакларын тотып карау,нәтиҗә ясау.<br>**Социальләштерү.**Д/у”Алсу урамга җыена “,<br>**Физкультура**.Х/у-р уйнау. |
| | II | Бәхетсезлек очракларын-нан ничек сакланырга? | Төрле бәла-казалардан сакланырга, ярдәм сорый белергә өйрәтү | |
| | III | Агач-куакларга якын җирдә уйнама! | Агач- куакларның кыш көне туңуын, төртелеп җәрәхәт алырга мөмкин икәнен аңлату. | |
| | IV | Аяк- кулларны салкыннан өшетмә! | Кыш көне урамда гел хәрәкәтләнеп торырга, суыктан сакланырга, җылы бияләй, носкилардан йөрергә кирәклекне аңлату | |
| февраль | I | Машина юлы һәм тротуар | Картинадагы рәсем буенча машина юлын һәм тротуарны аңларга өйрәтү. | **Физкультура.**Х/уен ”Җәяүлеләр һәм шофёрлар”<br>**Аралашу**.Әңгәмә,мульт-фильм карау.<br>**Матур әдәбият уку.** “Кәҗәбәтиләре һәм бүре”<br>**Аралашу.**Әңгәмә |
| | II | Кыен хәлдән чыгу юллары | Кыен очраклардан чыгу юлларын аңлату | |
| | III | Син өйдә берүзең | Газ һәм электр җиһазларына кагылмаска, тавышланып уйнамаска, ишек һәм тәрәзәне ачмаска өйрәтү. | |
| | IV | Әгәр син урамда адашсаң! | Урамда адашсаң, үзеңне ничек тотарга кирәклекне аңлату. | |
| март | I | Бер-береңә игътибарлы бул! | Балаларны уйнаганда бер-беренә игътибарлы булырга, бәрелү, егылулардан сакланырга, ярдәм кулы сузарга өйрәтү. | **Физкультура.** Х/уен-р ”Кошлар очалар”, ”Чыпчыклар һәм автомобиль”.<br>**Танып белү**. Боз сөңгеләрен урамда һәм рәсемнәрдә карау.<br>**Танып белү**. Күзәтү, тирән карга басып карау,нәтиҗә чыгару. |
| | II | Боз сөңгеләре | Боз сөңгеләре эленеп торган җирләрдә уйнарга ярамаганын аңлату. | |
| | III | Тирән карга кермә! | Яз көне карның эреп көпшәкләнүен, убылуын һәм кар | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | астында калырга мөмкин икәнен аңлату. | **Танып белү**.Автобус тукталышы билгесе белән танышу. |
| | IV | Без тукталышта. | Автобус көтү урыннарында уйнарга ярамаганлыкны аңлату | |
| апрель | I | «Урамдаятим хайваннар» | Авыр очраклардан чыгу юлларын аңлату | **Иҗади сәнгать:** рәсем«Мин хайваннарны яратам»; күргәзмә оештыру «Үз кулларың белән ясалган светофор.<br>**Физкультура:**хәрәкәтле уеннар “Төсле автомобильләр”, “Чыпчыклар һәм автомобиль”<br>**Коммуникация:** әңгәмә“Без урамда уйныйбыз” |
| | II | «Безнең ярдәмчеләр». *Дидактик уен* «Сөйләшүче юл билгеләре» | Алган белемнәрне кулланып юлда йөрү күнекмәләрен камилләштерү, светофор турында белемнәрен ныгыту | |
| | III | «Урманда үзеңне ничек тотарга?» | Урманда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән танышу, янгын чыганакларын кисәтергә өйрәтү. | |
| | IV | «Зарарлы үсемлекләр» | «Зарарлы үсемлекләр» төшенчәсе белән таныштыру, урманда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту. | |
| май | I | «Юлда җәяүле». *Дидактик уен* «Светофорны җый» | Алган белемнәрне кулланып юлда йөрү күнекмәләрен камилләштерү, светофор турында белемнәрен ныгыту | **Иҗади сәнгать:** рәсем«Мин балалар бакчасына барам»; күргәзмә оештыру «Үз кулларың белән ясалган светофор.<br>**Физкультура:** хәрәкәтле уеннар “Төсле автомобильләр”, “Чыпчыклар һәм автомобиль” **Коммуникация:**әңгәмә“Без урамда уйныйбыз” |
| | II | «Өйгә таба юл». *Дидактик уен* «Микрорайон буенча сәяхәт» | Микрорайон макеты буенча хәрәкәтләнү буенча белемнәрен киңәйтү. Өйгә кайту юлында тәртип кагыйдәләрен ныгыту | |
| | III | «Мин юл йөрү кагыйдәләрен беләм» | Төрле юл ситуацияләреннән чыгу юлларын өйрәтү. | |
| | IV | «Юлда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре». *Сюжетлы – рольле уен* «Йөртүчеләр һәм җәяүлеләр» | Юл йөрү билгеләре, юлда үз-үзләрен тоту кагыйдәләре турындагы белемнәрен ныгыту. | |

## 2.3.2. «ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ» белем бирү өлкәсе

***ЭЛЕМЕНТАР МАТЕМАТИК ТӨШЕНЧӘЛӘР ФОРМАЛАШТЫРУ***

***Аңлатма язуы***

Элементар математик төшенчәләр формалаштыру баланың акыл үсешендә зур урын алып тора. Оештырылган белем бирү эшчәнлегендә күп төрле дидактик уеннар кулланыла, логик мәсьәләләр чишелә.

Ел ахырына балалар алган белемнәр:

САН. Балаларны бер төрле предметларны төркемләргә өйрәтү.Предметларның санын аерырга өйрәтү:күп-бер;күп-аз.

ЗУРЛЫК. Предметларны зурлыклары буенча аерырга өйрәтү ( зур-кечкенә)

ФОРМА. Предметларны формасы буенча танырга өйрәтү (шар,шакмак һ.б.)

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | “ТУП” | 1) предметларны дөрес әйтергә өйрәтү ;<br>2) предметларны форма буенча аера белүләрен үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | II | “ТУП” | 1) предметларны дөрес әйтергә өйрәтү ;<br>2) предметларны формасы, төсе буенча аера белүләрен үстерү;<br>3) Үзара ярдәм, коллективта эшли белү, төгәллек кебек сыйфатлар тәрбияләү. |
| | III | “Предметларның хәрәкәт торышы” | 1) предметларның хәрәкәт торышын билгеләргә өйрәтү ;<br>2) предметларны формасы, төсе буенча аера белүләрен үстерү;<br>3) коллективта шөгыльләнү, сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. |
| | IV | “Предметларның хәрәкәт торышы” | 1) предметларның хәрәкәт торышын билгеләргә өйрәтү ;<br>2) предметларны формасы, төсе буенча аера белүләрен үстерү;<br>3) коллективта шөгыльләнү, сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. |
| октябрь | I | “Шар һәм куб” | 1) предметларны дөрес әйтергә өйрәтү ;<br>2) предметларны форма буенча аера белүләрен үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | II | “Шар һәм куб” | 1) шар һәм кубны аера, атый белүләрен ныгыту ;<br>2) предметлар белән хәрәкәтләр ясауны (тәгәри,кую) камилләштерү;<br>3) сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | “Шар һәм кирпич” | 1) шар һәм кирпичне аера, атый белүләрен ныгыту ;<br>2) предметлар белән хәрәкәтләр ясауны (тәгәри,кую) камилләштерү;<br>3) үзара ярдәм, яшьтәшләре коллективында белү сыйфатлар тәрбияләү. |
| | IV | “Куб һәм кирпич” | 1) куб һәм кирпичне аера, атый белүләрен ныгыту ;<br>2) гади корылмалар ясауны камилләштерү;<br>3) уенчыкларга сакчыл караш һәм уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| ноябрь | I | “Куб, шар һәм кирпич” | 1) куб, шар һәм кирпичне аера, атый белүләрен ныгыту ;<br>2) предметлар белән хәрәкәтләр ясауны (тәгәри,кую) камилләштерү;<br>3) үзара ярдәм, яшьтәшләре коллективында белү сыйфатлар тәрбияләү. |
| | II | “Зур һәм кечкенә” | 1) зур һәм кечкенә сүзләрен куллану белүләрен ныгыту ;<br>2) әйләнә-тирәдәге предметларны танып белүгә кызыксынуларын үстерү;<br>3) әйләнә-тирәгә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | III | “Зур һәм кечкенә” | 1) зур һәм кечкенә сүзләрен куллану белүләрен ныгыту ;<br>2) предметлар белән хәрәкәтләр ясауны камилләштерү;<br>3) әйләнә-тирәгә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | IV | “Зур шакмак һәм кечкенә шакмак” | 1) зур һәм кечкенә сүзләрен куллану белүләрен ныгыту ;<br>2) гади корылмалар төзүне камилләштерү;<br>3) әйләнә-тирәгә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | V | “Зур шакмак һәм кечкенә шакмак” | 1) зур һәм кечкенә сүзләрен куллану белүләрен ныгыту ;<br>2) гади корылмалар төзүне камилләштерү;<br>3) уен барышында балаларның үз-үзләрен дөрес тота белүләрен тәрбияләү. |
| декабрь | I | “Зур шар һәм кечкенә шар” | 1) зур һәм кечкенә сүзләрен куллану белүләрен ныгыту ;<br>2)предметлар белән төрле хәрәкәтләр ясауны камилләштерү;<br>3) әйләнә-тирәгә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | II | “Төрле зурлыктагы куб һәм шар” | 1) төрле зурлыктагы куб һәм шарны аера белүләрен ныгыту;<br>2) зурлыклары буенча предмедлар төркеме төзүне камилләштерү;<br>3) сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. |
| | III | “Күп һәм бер” | 1) саны буенча предмет төркемнәрен аера белүләрен ныгыту ;<br>2) балаларның игътибарын, үрнәк буенча эшли белүләрен үстерү;<br>3) сорауларга җавап бирү теләге, кулланылган материалга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | IV | “Бер - күп” | 1) саны буенча предмет төркемнәрен аера белүләрен ныгыту;<br>2) тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирә белүләрен үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) сорауларга җавап бирү теләге, кулланылган материалга сакчыл караш  тәрбияләү. |
| гыйнвар | I | “Күп-күп” | 1)“Күп” төшенчәсен  өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | II | “Күп-бер, бер-күп” | 1)“Күп” төшенчәсен  өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | III | “Зур-кечкенә” | 1) “Зур-кечкенә” төшенчәсен  өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| февраль | I | “Күп-аз, аз-күп” | 1) Әйбернең формасын таный белергә өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | II | “Бер-күп” | 1) Әйбернең формасын таный белергә өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | III | “Күп-күп” | 1) Әйбернең күләмен төркемләргә  өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга кызыксыну  тәрбияләү. |
| | IV | “Күп-күп” | 1) Зур һәм кечкенә пирамидаларны куллана белергә өйрәтү;<br>2) Геометрик фигуралар турында алган белемнәрен ныгыту;<br>3) Уенчыкларга карата сак караш тәрбияләү. |
| Март | I | “Күп-бер, бер-күп, күп-күп” | 1)Предметларны размерлары буенча чагыштыру;<br>2) үсә бару тәртибендә урнаштыру күнекмәләрен системалаштыру.<br>3) Бер-берсенә карата хөрмәт тәрбияләү. |
| | II | “Зур-уртача-кечкенә” | 1)3 предметны бер – берсе белән чагыштырырга өйрәтү;<br>2)пространствода ориентлашу күнекмәләрен системалаштыру;<br>3) уенчыкларга карата сак караш тәрбияләү. |
| | III | “Форма” | 1)3 предметны бер – берсе белән чагыштырырга өйрәтү;<br>2)пространствода ориентлашу күнекмәләрен системалаштыру;<br>3) уенчыкларга карата сак караш тәрбияләү. |
| | IV | “Форма” | 1)3 предметны бер – берсе белән чагыштырырга өйрәтү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2)простраствода ориентлашу күнекмәләрен системалаштыру;<br>3) уенчыкларга карата сак караш тәрбияләү. |
| | V | “Шар, шакмак” | 1)3 предметны бер – берсе белән чагыштырырга өйрәтү;<br>2)простраствода ориентлашу күнекмәләрен системалаштыру;<br>3) уенчыкларга карата сак караш тәрбияләү. |
| апрель | I | “Күләм һәм төс” | 1)Әйбернең күләмен һәм санын таный белергә өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | II | “Пространствода ориентлашу” | 1) Әйбернең күләмен һәм санын таный белергә өйрәтү;<br>2) Яңа сүзләр хисабына сүзлек запасын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | III | “Күп-аз” | 1) Әйберләрнең күп-аз икәнен таный белергә өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | IV | “Күп-аз” | 1) Әйберләрнең санын таный белергә өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| май | I | “Күп-аз” | 1) Әйберләрнең санын таный белергә өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | II | “Зур-кечкенә” | 1) Әйберләрнең формасын таный белергә өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | III | “Шар һәм шакмак” | 1) Шар һәм шакмакны аера белү.;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | IV | “Күләм һәм төс” | 1)Әйбернең күләмен һәм санын таный белергә өйрәтү;<br>2) Игътибарлылык сыйфатларын үстерү;<br>3) Уенга уңай караш тәрбияләү. |
| | V | “Кабатлау” | Алда алган белемнәрен ныгыту. |

### *ПРЕДМЕТЛЫ ТИРӘЛЕК, СОЦИАЛЬ ДӨНЬЯ, ТАБИГАТЬ ДӨНЬЯСЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ*

***Аңлатма язуы***

«Танып белү үсеше» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын ҺӘМакылныүстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә ҺӘМ белем бирү бурычларын билгели.

Балаларны әйләнә - тирәдәге предметларның исемнәре белән таныштыру эшен дәвам итү:уенчыклар, савыт- саба, өс киемнәре, аяк киемнәре, йорт җиһазлары, транспорт чаралары. Предметларның төсен, формасын, зурлыгын, нинди материалдан (кәгазь, агач, тукыма эшләнгән булуын әйтә белергә; таныш әйберләрне чагыштырырга (төрле башлыклар, бияләйләр, аяк киеме һ.б.); бертөсле, охшаш әйберләрне табарга (шундыйны ук тап, парын тап һ.б.) функцияләреннән (файдалану ысулыннан) чыгып төркемнәргә (чынаяктан чәй, җимеш суы эчәргә) өйрәтү.Балаларның предметлар белән эш- гамәлләр башкару ихтыяҗын тормышка ашырырга булышлык итү. Теге яки бу әйбернең ни өчен кирәк булуын, аларны ничек кулланырга мөмкинлеген аңлату.

**Гаилә.** Баланы узенең йортын,фатирын танырга; уз исемен һәм гаилә әгъзаларының исемнәрен әйтә белергә өйрәтү. Якыннарының хәленә керә белүчәнлек тәрбияләү (кызгану,ярдәм итү һ.б.).

Кеше яши торган торак төзелеше (шәһәрдә һәм авылда), йорт кирәк-яраклары турында күзаллаулар булдыру. Кеше кулы белән ясалган җайланмаларның төзелеше һәм билгеләнеше турында сораулар бирергә, һәр яңалык белән танышырга омтылыш тәрбияләү.

**Балалар бакчасы.** Үзләре йөргән балалар бакчасын танырга, төркем бүлмәсен табарга өйрәтү. Үз тәрбиячеләре, тәрбияче ярдәмчесе, балалар бакчасының башка хезмәткәрләренә карата ышану, ярату хисләре булдыру өчен шартлар тудыру.Яшьтәшләренә карата игътибарлы, ягымлы булырга өйрәтү.Башкалар белән сугышырга, аларга карата дорфа, тупас мөгамәләдә булырга ярамаганлыгын аңлату.Төркем бүлмәсендә, мәйданчыкта ориентлаша белергә өйрәтү;төп биналарны, корылмаларны (төркем бүлмәсе, баскыч, веранда,комлык һ.б.) әйтә белергә күнектерү.

**Туган ил.** Үзләре яши торган шәһәр (бистә, авыл), урам исемнәрен балаларның исләренә төшереп тору.

**Өлкәннәр хезмәте.** Балаларда якыннарының хезмәтенә карата кызыксынучанлык тәрбияләү. Кайбер эш төрләрен аңлап әйтергә өйрәтү (тәрбияче ярдәмчесе савыт-саба юа, бүлмә җыештыра, ашарга алып килә, сөлгеләрне алыштыра һ.б.).

**Экологик тәрбия.** Балаларда табигать белән кызыксынучанлык тәрбияләү: үсемлекләр (үлән, агач) турындагы күзаллауларын киңәйтү,бүлмә гөлләре белән таныштыру (яфракларын, чәчәкләрен күрсәтү), йорт хайваннарын (песи һәм песи балалары, эт һәм көчекләр һ.б.) күзәтү, йорт кошлары (әтәч,тавык,чебиләр һәм балалар бакчасындагы мәйданчыкка килгән кошлар (чыпчык,карга) белән таныштыру.

Үзләре яшәгән җирдә үскән кайбер яшелчә, җиләк – җимешләрне тышкы билгеләре һәм тәмнәренә карап аера белергә өйрәтү.

Балалар белән бергәләп табигатькүренешләрен күзәтү һәм аларның матурлыгын (кар бортекләре оча, яфраклар ява, күктә салават күпере күренде, гөлләр чәчәк ата һ.б. ) күрергә ойрәтү. Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында сөйләү.

***Комплекслы – тематик план***

| ай | атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | I | Йомшаккай бездә кунакта | 1) балаларның уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтү, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын формалаштыру, уенчык исемнәре һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру;<br>2) тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләген үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, уенчык ларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | II | Йомшаккай тагын бездә кунакта | 1) уенчыкларны карарга һәм аерым өлеш ләрен билгеләргә өйрәтү; уенчыкларның исемен, өлешләрен әйтү, төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертү;<br>2) тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, кызыклы уенчыклар белән уйнаудан тәм табу, шатлык хисләре тәрбияләү. |
| | III | Тупны коткарабыз | 1) рәсемнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне һәм фразаларны актив кабатлауларын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | IV | Юыну бүлмәсен карау | 1) балаларны юыну бүлмәсендәге предметлар (сабын, сөлге, кран, су, теш щёткасы, теш пастасы) белән таныштыру, функциональ билгеләнешләре турындагы күзаллауларын ачыклау;<br>2) сүзләрне төрле грамматик формаларда (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.) куллану осталыгына ирешү, балаларның сөйләм активлыгын, инициативасын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү,пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү омтылышы тәрбияләү. |
| неоябрь | I | Көзге табигать | 1) балаларның көз (табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең киеме һ.б.) турында гади күзаллауларын формалаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү;<br>3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| | II | Җиләк-җимешләр | 1) тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турында күзаллауларын киңәйтү, җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм аларның билгеләрен белдерә торган сүзләрхисабына балаларның сүз байлыгын үстерү;<br>2) балаларның игътибарын, үзләштерү, кабул итү һәм сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | осталыгын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белергәгадәт лән дерү, әйләнә-тирә табигать объектларына кызыксыну тәрбияләү. |
| | III | Безнең Алсу”сериясеннән рәсем карау | 1) рәсемдәге предметларны таный һәм исемен әйтә белергә, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләренә ирешү;<br>3) рәсемне кызыксынып карау теләге тәрбияләү. |
| | IV | Яшелчәләр: помидор,кыяр, кишер белән таныштыру | 1) балаларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгыту; помидор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл, хуш исле, шар формасындагы помидор; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер) белән таныштыру;<br>2) балаларның сенсор тою сәләтен, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, зурлар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. |
| | V | Рәсемдәге кошларны карау | 1) балаларда күгәрчен, саескан турында гомуми күзаллаулар булдыру, кошларга карата кызыксыну уяту;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген һәм сүз байлыгын үстерү;<br>3) кошларга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| | I | “Көз” (йогаклау чарасы | 1) балаларның көз турындагы белем нәрен (яфраклар саргая, сары яфраклар , яфраклар коела, яңгырлар күп ява, кешеләр җылы кием нәрен кияләр) ныгыту, тәр бияче сорауларына дөрес җавап бирергә, рәсем ясаганда, буяуны кәгазь битенә дөрес һәм тигез төше рергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту;<br>2) балаларның актив сөйләмен, ишетеп кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, рәсем ясарга кызыксындыру;<br>3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| | II | Минем исемем бар | 1) баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү;<br>2) тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайберфразаларны (Минем исемем — Алсу) кабатларга күнектерү, хәтерне, игътибарны үстерү;<br>3) балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Бу- мин | 1) организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштыру, үзләрен бербөтенитеп кабул итәргә өйрәтү, гәүдә өлешләре турында белемнәрне ачыклау һәм ныгыту;<br>2) гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәч, куллар, аяклар)хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>3) үзеңне, гәүдә өлешләреңне ярату, игътибарлы булу, культура-гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру. |
| декабрь | IV | Яраткан уен бүлмәбез | 1)Балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам итү, төркемдәге уен бүлмәсе, андагы махсус почмаклар белән таныштыру, “һәр әйбернең үз урыны” дигән төшенчәне аңлату һәм ныгыту;<br>2)Сүзләрне һәм фразаларны ачык әйтүләренә ирешү, сүз байлыгын үстерү; |
| | I | “КамАЗ” мшинасы | 1) балаларны КамАЗ машинасын һәм аның өлеш ләрен танырга, исемен әйтергә өйрәтү; уенның сүз ләренә туры китереп, хәрәкәтләр ясау осталыгы булдыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, эмоциональлеген үстерү;<br>3) балаларда йөк транспортына, өлкәннәр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. |
| | II | Гирлянда | 1) балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү, электр тогы турындагы күз ал лауларын ныгыту, кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, шатлык хисләрен үстерү, сүз байлыгын киңәйтү;<br>3) күмәк эшчәнлектә катнашу теләге тәрбияләү. |
| | III | Яшел чыршы | 1) балалар белән бергәләп чыршыны карау, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм баету;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүз байлыгын активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчән леген, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) матурлыкны күрә һәм аңа соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | IV | Безнең урам | 1)балаларны урам белән таныштыру;<br>2)игътибарын арттыру;<br>3)урамга соклану хисе тәрбияләү. |
| январь | I | Күгәрченнәр, чыпчыклар – безнең нәни кошчыклар | 1) мәйданчыктагы җимлеккә килгән кошларны күзәтү, исемнәрен әйтү; гөр-гөр, чырык-чырык, кар - кар аваз ияртем нәрен ачык әйтергә күнектерү; томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер сүзләре хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | Йорт хайваннары | 1) балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү;<br>2) сүзлекне баету, тәрбияченең сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбия ләү. |
| | III | Җәнлекләр урманда яшиләр | 1) җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ныгыту, җәнлекләрне таный һәм исем нәрен атый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү;<br>3) җәнлекләр белән кызыксындыру. |
| февраль | IV | Алсу бәйрәмгә җыена | 1) өс киемнәре, аларның төсе һәм материалы беләнтаныштыруны дәвам итү, сүзлекне активлаштыру: ефәк, ак чәчәкле кебек яңа сүзләр кертү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сорауларны ишетү, аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыкларын үстерү;<br>3) курчаклар белән уйнарга теләк уяту, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | I | Кибеткә барабыз | 1) бәйләнешле сөйләмне устерү,өйрәнелгән сүзләрне актив сүзлеккә кертү.<br>2) кибеттә үз-үзеңне әдәпле тотуның иң гади кагыйдәләрен үтәргә теләк тудыру. |
| | II | Транспорт төрләре белән таныштыру | 1) балаларны транспорт төрләрен таный белергә, исемнәрен әйтергә өйрәтү.<br>2) балаларда күзаллау сәләтен үстеру.<br>3) транспортта барганда кычкырып сөйләшергә ярамаганлыгын аңлату. |
| | III | Безнең әтиләр | 1) балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәр карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүз байлыгын үстерү;<br>3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә<br>карата кызыксыну уяту. |
| | IV | Безнең әниләр | 1) балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| март | I | Кеше әгъзалары | 1) кеше әгъзаларын аңлата торган сүзләрне кулланышка кертү<br>2) әйе,юк сүзләрен сөйләмдә ныгыту.<br>3) балаларда чисталыкка омтылыш тәрбияләү. |
| | II | Матрёшкалар | 1) уенчыкның (матрёшканың) исемен дөрес әйтергә,төсендә һәм зурлыгында булган аермалыкларны<br>күрә белергә күнектерү; зур, кечкенә, сарафан, яулык сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) балаларда халык уенчыкларына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | III | Яз, яз килә | 1) балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү;<br>3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |
| | IV | Безнең апа | 1) тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш-хәрәкәтләрне әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну тәрбияләү. |
| апрель | I | Урманда яз | 1) балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү;<br>3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |
| | II | Тузганак чәчәген карау. | 1) балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү, тузганак чәчәген күрсәтү, аны танырга, исемен әйтергә, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтү; сүз байлыгын киңәйтү; тузганак, чәчәк, сабак сүзләрен сөйләмдә активлаштыру;<br>2) балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уяту, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| | III | Сыерчыклар, карлыгачлар килде (рәсемнәр карау). | 1) балаларны үзләренә таныш кошларны рәсемнән танырга, исем нәрен әйтергә өйрәтү; балаларның сүз байлыгын арттыру, сүзлеккә сыерчык, сыерчык оясы, карлыгач сүзләрен кертү;<br>2) игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) кошлар һәм табигать белән кызыксынуларына ирешү, кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | Песиле тал бөреләрен карау | 1) балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштыру, табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү, сүз байлыгын киңәйтү һәм песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) табигать белән кызыксыну, табигать матурлыгына соклану хисләре тәр бияләү. |
| | V | Балалар тавык һәм чебиләр ашата | 1) балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшлә рен тыңларга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) сөйләмне томшык, тавык, чебиләр, табак сүзләре хисабына баету, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү;<br>3) йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| май | I | Йорт хайваннары | 1) балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү;<br>2) сүзлекне баету, тәрбияченең сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбия ләү. |
| | II | Экология сукмагы буенча сәяхәт | 1) ”Яз” темасы караган сүзләрне активлаштыру, сөйләмдә ныгыту.<br>2) тирә-юньдәге усемлекләр турындагыкүзаллауларын ныгыту.<br>3) балаларда табигать белән кызыксынучанлык һәм аңа сакчыл караш тәрбияләү. |
| | III | Ком һәм аның үзлекләре | 1) балаларны комны тикшерергә (комны учка алырга, йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү;<br>2) коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү сүзләре хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү, игътибарын,<br>сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) ком белән уйнарга кызыксындыру. |
| | IV | Чәчәкләр | 1)балаларның чәчәкләр турында белемнәрен арттыру;<br>2)диалогик сөйләм күнекмәләрен булдыру;<br>3)соклана белү хисләре тәрбияләү. |

***Конструкцияләү***

***Аңлатма язуы***

Материалларының аерым детальләре (шакмак, кирпич, түбә (өчкырлы призма), цилиндр, такиа (пластина) белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның иң гади конструкцияләү осталыкларын үстерү.

Үрнәк буенча гади генә корылмалар төзи белүләренә ирешү, мөстәкыйль рәвештә нәрсә дә булса төзү теләкләрен хуплау.

Корылмаларның үлчәмнәренә туры китереп, (кечкенә машиналар өчен кечкенә гараҗлар), өстәмә сюжетлы уенчыклар кулланырга, өлкәннәр белән бергәләп кечкенә манаралар һәм өйләр, машиналар төзергә өйрәтү.

Җәйге чорда төзелеш уеннарында табигать материалларын кулланырга өйрәтү.

Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр:

- Төзелеш материаллары детальләренең төп формаларын белү;
- Күпчелек формаларны кулланып, өлкәннәр ярдәме белән төрле корылмалар төзү.
- Корылмалары белән уеннар оештырырга өйрәтү.

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| Сентябрь. Тема: «Өйдәгез танышабыз!" | I | “Әтәчкә өй” | Балаларны төзү материаллары һәм алардан төрле корылмалар төзергә мөмкин булуы белән кызыксындыру. Геометрик фигуралар: шакмак, призма белән таныштыру. |
| | II | “Эт өчен өй” | Төзү материаллары белән таныштыруны дәвам итү, төзегән әйбергә игътибар тупларга һәм эчке кичерешләрне сүз белән әйтә белергә өйрәтү. |
| | III | “Куянга өй” | Геометрик фигуралар: зур һәм кечкенә шакмаклар, призма белән таныштыруны дәвам итү, төзеп һәм уйнап күрсәткәндә тәрбиячегә булышырга теләк тудыру. |
| | IV | “Алсу өчен урындык” | Төзү материаллары: призма һәм шакмак белән таныштыруныдәвам итү, геометрик фигуралар белән гади төзелешләр башкарырга теләк тудыру. |
| Октябрь. Тема: “Күзне кунакка чакырабыз” | I | “Ике зәңгәр шакмактан башня төзү” | Төзү материаллары: кирпич һәм шакмак белән танышу, зәңгәр төсне аерырга өйрәтү. |
| | II | “Өч сары шакмак белән башня төзү” | Шакмак һәм призма кулланып төзи белү осталыгын камилләштерү, сары төсне танырга, төзү алымын (шакмак өстенә шакмак кую) өйрәтү. |
| | III | “Дүрт яшел кирпичтән башня төзү” | Кирпичләр һәм призма кулланып төзи белү осталыгын камилләштерү, яшел төсне танырга, төзү алымын (шакмак өстенә шакмак кую) өйрәтү. |
| | IV | “Дүрт кызыл кирпичтән башня төзү” | Кирпичләр һәм призма кулланып төзи белү осталыгын камилләштерү, кызыл төсне танырга, төзү алымын (шакмак өстенә шакмак кую) өйрәтү. |
| Ноябрь. Тема: «Урман | I | “Шакмак һәм кирпичләрдән өстәл белән урындык” | Берьюлы ике төрле төзү материалы (шакмак һәм кирпич) белән эшләргә, сары төсне танырга һәм әйтә белергә өйрәтү. |
| | II | “Яшел өстәл һәм ике сары урындык” | Берьюлы ике төрле һәм ике төсле төзү материалы (шакмак һәм кирпич) белән эшләргә, тйзү детальләрен формасы һәм төсе буенча аерырга, танырга өйрәтү. |
| | III | “Өстәл һәм зәңгәр кресло” | Төзү материалларын формасы һәм төсе буенча аера белергә өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | “Төрле төстәге өстәл һәм урындык” | Корылмаларны төсе буенча аера белергә өйрәтү. |
| Декабрь. Тема: “Җәнлекләрдә | I | “Төрле төсле юл” | Кирпичләр белән эш итә белүне ныгыту, форма һәм төсләрне аерырга өйрәтү. |
| | II | “Тар, сары юл” | Төзү материалларын тар ягы белән куеп эшләргә, сары төсне танырга һәм әйтергә өйрәтү. |
| | III | “Киң кызыл юл» | Төзү материалларын киң ягы белән куеп эшләргә, кызыл төсне танырга һәм әйтергә өйрәтү. |
| | IV | “Бер үк төстән туп һәм юл» | Төсләре буенча төзү детальләрен танырга һәм әйтә белергә өйрәтү. |
| Гыйнвар. Тема: “Кышкыуеннар” | I | “Койма” | Үрнәктән файдаланып, төзү материалын озын ягына кую алымын кулланып, эшләргә өйрәнү. |
| | II | “Койма” | Кирпичне тар ягы белән кую алымын кулланып эшләргә өйрәнү. |
| | III | “Шакмак һәм кирпичләрдән койма” | Төзү материалларын чиратлаштырып куеп төзергә өйрәтү. |
| | IV | “Зәңгәр шакмак һәм кызыл кирпичтән койма” | Зурлыгы һәм төсе төрле булган детальләрдән койма төзи белү осталыгын үстерү, геометрик фигуралар: кирпич, шакмакны әйтә белергә өйрәтү. |
| Февраль.тема: “Транспорт” | I | “Кечкенә машина” | Яңа төзү детале – пластина белән танышу, төзү материалларын берсе өстенә берсен куеп төзергә өйрәнүне дәвам итү. |
| | II | “Автобус” | Төзү детальләрен берсе өстенә берсен куеп төзи белү осталыгын үстерү. |
| | III | “Үрнәк буенча автобус һәм йөк машинасы төзү” | Үрнәккә карап,аңлату юлы аша төзергә өйрәнү. |
| | IV | “Поезд” | Зурлык һәм төс төшенчәләрен ныгыту, төзү эзлеклелеген аңлата белергә өйрәтү. |
| Март. Тема: Язгы чынлау” | I | “Матрешкалар өчен эскәмия” | Яңа алым – төзү детальләрен тоташтырырга өйрәтү. |
| | II | “Зур һәм кечкенә эскәмия” | Төзү детальләре һәм корылмалары буенча аера белергә өйрәнү. |
| | III | “Капка һәм койма” | Төзи алымнарын аңлатмаган килештә, төзи белергә өйрәтү. |
| | IV | “Төрле төсле корылмалар” | Төсе һәм формасы буенча төрле булган төзү детальләрен (кирпич, шакмак, пластина) кулланып төзергә өйрәнүне дәвам итү. |
| Апрель. Тема: “Безнең булышчылар” | I | “Түбәле өй» | Яңа төзү детале – призма белән эшли белүне ныгыту. |
| | II | “Өй” | Төзү материалларын формасы, төсе, зурлыгы буенча аера һәм атый белергә, тйзү эзлеклелеген аңлата белергә өйрәтү. |
| | III | “Үрнәк буенча өй » | Төп төзү алымнарын (кую, өстенә кую, яткыру, салу, каплау) кулланып эшли белүне, төзү детальләрен чиратлаштыра белүне камилләштерү. |
| | IV | “Тәрәзәле өй” | Ел буе өйрәнгән эш алымнарын, төзи белү осталыкларын ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| май | I | “Алда үткәннәрне кабатлау” | Ел буе өйрәнгән алымнарны кулланып, теләк буенча төрле корылмалар төзеп уйлау. |
| | II | “Зәңгәр шакмак һәм кызыл кирпичтән койма” | Зурлыгы һәм төсе төрле булган детальләрдән койма төзи белү осталыгын үстерү, геометрик фигуралар: кирпич, шакмакны әйтә белергә өйрәтү. |
| | III | “Автобус” | Төзү детальләрен берсе өстенә берсен куеп төзи белү осталыгын үстерү. |
| | IV | “Куянга өй” | Геометрик фигуралар: зур һәм кечкенә шакмаклар, призма белән таныштыруны дәвам итү, төзеп һәм уйнап күрсәткәндә тәрбиячегә булышырга теләк тудыру. |

### 2.3.3. «СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ» белем бирү өлкәсе

***СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ***

***Аңлатма язуы***

**Сөйләм үстерү мохите.** Аралашу чарасы буларак,балаларның сөйләмнәрен үстерүгә булышлык итү. Иптәшләре һәм өлкәннәр белән аралашу мөмкинлеге бирә торган төрле йомышлар кушу (“ Чишенү бүлмәсенә кара але,  кем килде микән?”,  “Алсу апаңнан бел һәм миңа сөйлә”,  “ Маратны кисәт.... Марат син нәрсә дидең? Марат нәрсә җавап бирде?”).

Балаларга мөстәкыйль карау,уйнау өчен китаплар, рәсемнәр, уенчыкла, предметлар (3-4 курчаклы матрешка, ачкыч белән борып хәрәкәткә китерә торган уенчыклар, конфет кәгазьләре салынган шкатулка һ.б.) тәкъдим итү.

Бу әйберләр, шулай ук кызыклы хәлләр, вакыйгалар (мәсәлән, йорт хайваннарының хәйләкәрлеге, аларнын яшәү рәвеше һ.б.) турында нәниләргә аңлаешлы, мавыктыргыч итеп сөйләү.

Тәрбияченең сөйләмен игътибар белән тыңларга гадәтләндерү.

**Сүз байлыгын үстерү**

Әйләнә – тирәдә ориентлашуны киңәйтү нигезендә башкалар сөйләмен аңлауларын үстерү, сүзлекләрен үстерү, сүзлекләлен активлаштыру.

Тәрбияченең кушуы буенча, әйберләрнең  төсе һәм зурлыгына карап, аларны табып китерергә (“кызыл машинаны алып кил”, Ак шарны тәгәрәт” , “Зур тупны мина бир”, “Кечкенә аюга җыр җырла”) ; урынын билгеләргә ( Кызыл машина югары киштәдә”, “Ак шар өстәл өстендә”, “Кечкенә туп өстәл астында»); кешеләрнең гамәлләрен һәм хайваннарның хәрәкәтләрен күрсәтергә ( аю булып йөреп күрсәт; гөлләргә ничек су сибәбез) өйрәтү.

**Авазларны дөрес әйтергә өйрәнү**

Сузык һәм тартык (сызгырулы, чыжылдаучы  һәм сонор авазлардан тыш)авазларны, аваз ияртемнәрен, аерым сүзләрне , 3-4 сүздән торган фразаларны дөрес әйтергә өйрәтү буенча күнегуләр башкару.

Артикуляция  һәм  тывыш аппаратын, Сулыш (тын) алуны һәм ишетү игътибарлылыгын үстерүгә булышлык итү.

Сөйләмдә тавышның югарылыгын һәм көчен куллана белүне (охшату буенча) формалаштыру “ Песи, прес-сс!”, “Кем килде?” , “ Кем шылтырата?”

**Бәйләнешле сөйләм**

Балаларны өлкәннәрнең сөйләмен аңларга һәм кечкенә дидактик хикәяләрне күрсәтмә материаллардан башка тыңларга өйрәнү . Гади ( “нәрсә бу?” “кем бу?” , “нәрсә эшли?”), тора – бара катлаулырак (“нәрсә кигән?”, “нәрсә алып бара?” , “ кемгә?” , “кайда?”, “кайчан?”) сорауларга җавап кайтара белүләренә итешү.

***Комплекслы – тематик план***

| **Ай** | **Атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | I | “Кем нәрсә эшли?” | 1) балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү, рәсемнәр карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын әйтергә, рәсемдә сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтү;<br>2) игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | II | «Предметларның төсләрен тану һәм атау”. “Паровоз” дидактик уены. | 1) төсләрне белдерә торган сыйфатлар (кызыл, яшел, сары) хисабына балаларның сөйләмен баету, [ү] ава зының дөрес әйтелешенә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерү;<br>3) эшчәнлеккә карата кызыксыну, бергәләп уйнау, шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| | III | “Уенчыклар бездә кунакта”. | 1) төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр (зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт) хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру, аралашу осталыгын формалаштыру;<br>2) исеме, төсе, размеры буенча балаларның предметны табу осталыгын, сенсор тою сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
